# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Әмәкәй авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

17.11.2023 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 нчы матдәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 нче матдәсе нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2023нче елның 17 нче ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2024 нче елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 (ике мең) сум күләмендә, I-II төркем инвалидлар, Афганстандагы һәм башка локаль конфликттагы сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге бүлекләрдә укучы студентларга 1000 (бер мең) сум күләмендә һәм ЛНР һәм ДНРДА махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны, шулай ук тормыш иптәшен (хатынын), балигъ булган балаларны, ә алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итеп үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

1. Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- кыш һәм җәй көннәрендә Әлмәт авылы эчендәге юлларны карап тоту, Ленин урамын кардан чистарту килешүе буенча хезмәтләр өчен түләү;
- юл буендагы үләннәрне чабу;
- юлларны подсыпкада грейдерлау.

2. Урам яктырту челтәрләрен ремонтлау:

- Ленин урамындагы урам яктырту өчен светодиодлы лампаларны сатып алу, ремонтлау һәм яңадан урнаштыру,
- урам яктырту челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү;
- материаллар сатып алу;

3. Су башняларын, скважиналарны су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системасын ремонтлау һәм аларга кушылган территорияләрне төзекләндерү:

- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, аварияләрне бетерү;
- су күтәрү манарасын электр белән тәэмин итү.

4. Ремонт, койма урнаштыру, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү:

- Иске Әлмәт авылы зиратыннан каты коммуналь калдыклар ташу;
- Иске Әлмәт зираты территориясендә үлән чабу.

«РИЗА» - «КАРШЫ»-

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 36 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 22, бу 61% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 22 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 0 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим униципаль районы Әмәкәй авыл җирлегенең Иске Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 нче елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 (ике мең) сум күләмендә,I-II төркем инвалидлар, Афганстандагы һәм башка локаль конфликттагы сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан 1000(бер мең) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- кыш һәм җәй көннәрендә Әлмәт авылы эчендәге юлларны карап тоту, Ленин урамын кардан чистарту килешүе буенча хезмәтләр өчен түләү;

- юл буендагы үләннәрне кисү;

- юлларны подсыпкада грейдерлау.

2. Урам яктырту челтәрләрен ремонтлау:

- Ленин урамындагы урам яктырту өчен светодиодлы лампаларны сатып алу, ремонтлау һәм яңадан урнаштыру,

- урам яктырту челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү;

- материаллар сатып алу;

3. Су башняларын, скважиналарны су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системасын ремонтлау һәм аларга кушылган территорияләрне төзекләндерү:

- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, аварияләрне бетерү;

- су күтәрү манарасын электр белән тәэмин итү.

4. Ремонт, койма урнаштыру, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү:

- Иске Әлмәт авылы зиратыннан каты коммуналь калдыклар ташу;

- Иске Әлмәт зираты территориясендә үлән чабу.

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Әмәкәй авыл җирлеге башлыгы : И.И.Шакирянова